**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеменең һәм Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук аерым затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме турында» 2012 елның 2 июнендәге ПУ-415 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1055 номерлы, 2015 елның 27 ноябрендәге ПУ-1130 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы, 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы һәм 2020 елның 2 маендагы ПУ-266 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме турында нигезләмәнең 9 пунктында:

«Татарстан Республикасы прокуратурасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

б) Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме (алга таба – эксперт төркеме) составында:

эксперт төркеме составыннан Р.Т. Борһановны, Н.Н. Хәбиповны чыгарырга;

эксперт төркеме составына кертергә:

Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

эксперт төркеме әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.И. Бикеевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының (Икътисад, идарә һәм хокук институты) беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)»;

А.Н. Кудрявцеваның – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры»;

Ф.М. Хәнифовның – «Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры»;

М.Р. Шаһиәхмәтовның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-914 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-717 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы, 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы һәм 2020 елның 2 маендагы ПУ-266 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында нигезләмәнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Комиссия составына Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппаратлары структур бүлекчәләре, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле аппараты бүлекчәләре, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, граждан җәмгыяте институтлары һәм оешмалар вәкилләре керә ала.»;

б) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан А.А. Кондратьеваны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Гатин Руслан Рафикъ улын – «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының икътисадый куркынычсызлык, сак һәм режим буенча урынбасарын (килешү буенча);

Фәттахов Дамир Илдус улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ш.Р. Агиевның – «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисе (килешү буенча)»;

И.И. Бикеевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты) беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)»;

М.Х. Сәлаховның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты»;

Ф.М. Хәнифовның – «Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры»;

М.Р. Шаһиәхмәтовның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры».

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 02 июнь
№ ПУ-425